| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.03.2017 Казан шәһәре № под-496/17

«Безнең иң яхшы мәктәп директоры»
гранты турында

Татарстан республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының иң уңышлы җитәкчеләрен ачыклау һәм нәтиҗәле идарә итү тәҗрибәсен тарату максатларыннан, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының (алга таба-министрлык) эш планы нигезендә б о е р а м:

1. «Безнең иң яхшы мәктәп директоры» грантын (алга таба-грант) гамәлгә кую.

2. 2017 елның 14 апреленнән 18 маена кадәр Грант алуга конкурс (алга таба - конкурс) оештырырга һәм үткәрергә.

3. Раслрга кушымта итеп бирелә торган:

3.1. Конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планын;

3.2. Конкурсны оештыру һәм үткәрүнең календарь планын;

3.3. «Безнең иң яхшы мәктәп директоры»гранты турында нигезләмәсен.

4. Чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы структур бүлекчәләр җитәкчеләренә һәм әлеге боерыкның 3.1, 3.2 пунктлары белән расланган планнарның үтәлешен тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә (Р. Бәдриевага) Конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итәргә.

6. Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә

(Г. Ф. Гатиятуллинага ) бәйгене оештыру һәм үткәрү белән бәйле финанслауны тәэмин итәргә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И. Р. Мөхәммәтовка йөкләргә

Премьер-министр урынбасары
Татарстан Республикасы-Министр Э.Н.Фаттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән Министрлыгының
28. 03.2017ел   № под-496/17
боерыгы белән

“Безнең иң яхшы мәктәп директоры” грантын алуга конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планы

| № п/п | Чара | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча гомуми җитәкчелек | Мухаметов И.Р.<br>Федорова Т.Т. |
| 2 | Конкурс үткәрү буенча смета төзү | Гатиятуллина Г.Ф.<br>Имамова Г.К. |
| 3 | Конкурс үткәрү программасын төзү | Федорова Т.Т.<br>Ахмерова Г.Р. |
| 4 | Конкурс сынаулары расписаниесен төзү. | Ахмерова Г.Р.<br>Мартьянова О.В. |
| 5 | Катнашучыларны теркәү, урнаштыруны оештыру. | Ахвердиева Г.А.<br>Зарипова Г.Д |
| 6 | Конкурста катнашучылар, жюри һәм оештыру комитеты әгъзалары өчен тарату материалы формалаштыру. | Алексеева М.В. |
| 7 | Бәйгене үткәрү көннәрендә фото һәм видеога төшерү.<br>Массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан конкурс барышын яктыртуны оештыру. | Мухаметова А.Д |
| 8 | Республика конкурс комиссиясе эшен координацияләү һәм тәэмин итү. | Федорова Т.Т.<br>Бадриева Р.Р.<br>Ахмерова Г.Р. |
| 9 | Конкурс үткәрү өчен оргтехника белән тәэмин итү | Кравцов А.А |

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән Министрлыгының
28. 03.2017ел № под-496/17
боерыгы белән

«Безнең иң яхшы мәктәп директоры» грант алуга конкурс оештыру һәм үткәрү календарь планы

| № п/п | Чара | Үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Конкурсны оештыру һәм үткәрү мәсьәләсе буенча оештыру комитеты киңәшмәсе | Март 2017 ел | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба-министрлык) |
| 2 | Директорлар укыту-методик эш буенча урынбасарлары белән киңәшмә . | Март 2017 ел | Министерлык |
| 4 | Муниципаль районнарның башкарма комитетлары мәгариф бүлеге (идарәләре) башлыклары белән киңәшмә | Март 2017 ел | Министерлык |
| 5 | Министрлык һәм «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесе » (алга таба — «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты” ӨҺББ ДАМУ) сайтларында грант алуга конкурс турында норматив-методик материалларны урнаштыру | Март 2017 ел | Министрлык «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты” ӨҺББ ДАМУ |
| 6 | (msairort@yandex.ru)электрон адрес буенча “Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ӨҺББ ДАМУнә конкурста катнашу өчен грантка | 2017 елның 14 апреленә кадәр | Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дәгъва кылучыларның документларын кабул итү | | |
| 7 | Грант алуга конкурсның беренче (читтән торып катнашу) туры | 14 апрель-8 май 2017 ел | Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты |
| 8 | Грант алуга Конкурсның беренче (читтән торып катнашу) турының беренче этапы | 17-19 апрель ае 2017 ел. | Республика конкурс һәм эксперт комиссиясе |
| 9 | Беренче (читтән торып катнашу) турының икенче этабында катнашу өчен Грантка дәгъва кылучыларның исемлеген бастырып чыгару | 21 апрель 2017 ел. | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе» |
| 10 | Апелляциялшр кабул итү һәм карау | 24-29 апрель 2017 ел | «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирүдәүләт автоном учреждениесе, Республика конкурс комиссиясе. |
| 11 | Грантка дәгъва кылучыларга өй эшен тарату | 2 май 2017 ел. | "Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты “ӨҺББ ДАМУ, Республика конкурс комиссиясе. |
| 12 | Беренче (читтән торып катнашу) турның өй эшен башкару | 5-8 май 2017 ел. | "Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты” ӨҺББ ДАМУ, Республика конкурс комиссиясе |
| 13 | Икенче (турыдан-туры) турда | 12 май | Министрлык, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашу өчен Грантка дәгъва кылучыларның исемлеген бастырып чыгару | 2017 ел | «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " ӨҺББ ДАМУ, Республика конкурс комиссиясе. |
| 14 | Конкурсның икенче туры | 15-17 май 2017 ел. | Министрлык, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " ӨҺББ ДАМУ |
| 15 | Грант алучылар исемлеген бастырып чыгару | 18 май 2017 ел | Министрлык, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАМУ |

Расланган

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән Министрлыгының
28. 03.2017ел № под-496/17
боерыгы белән

«Безнең иң яхшы мәктәп директоры » гранты турында
Положение

1. Гомуми положениеләр

1. 1. "Безнең иң яхшы мәктәп директоры» грантын (алга таба - грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела.

Чарада грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы катнаша.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба — министрлык).

Грантка дәгъва кылучы - Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе һәм грант алуга конкурста катнашучы.

Грант алучы- Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе.

Грант алучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү грант булып тора:

11-20 урын алган 10 гомуми белем бирү оешмалары җитәкчләренә (лауреатларга) 100 000әр (меңәр) сум күләмендә ;

6-10 нчы урын алган 5 гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә (призерларга) 150 000 әр(йөз илле меңәр) сум күләмендә;

2-5 урыннарны алучы 4 гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә (җиңүчеләргә) 200 000әр (ике йөз меңәр) сум күләмендә;

1 урын алган гомуми белем бирү оешмасының бер җитәкчесенә (абсолют җиңүчегә) 250 000 (ике йөз илле мең) сум күләмендә.

1.2. Әлеге Положение 2017 елда Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.3. Конкурс мәгариф оешмалары белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча белем бирү оешмалары җитәкчеләренең иҗади эшчәнлеген үстерүгә, "Федераль белем бирү стандартларын (алга таба-ФГОС) исәпкә алып,

”Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру кысаларында, белем бирү процессын оештыруда инновацион технологияләрне куллануга ярдәм итү, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең һөнәри осталыгын үстерү, җәмгыятьтә белем бирүнең өстенлеген раслауга юнәлдерелгән.

1.4. Конкурсны оештыруның төп принциплары:

иреклелек;

ачыклык;

гаделлек;

барлык катнашучыларның мөмкинлекләре тигезлеге.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты-гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.

2.2. Конкурсның бурычлары булып тора:

гомуми белем бирү оешмаларының иң уңышлы җитәкчеләрен ачыклау; Татарстан Республикасында урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының иң яхшы җитәкчеләренең нәтиҗәле идарә итү тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату;

гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең Татарстан Республикасы мәгариф системасын үстерүгә керткән шәхси өлешен халык алдында тану;

гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең уңай имиджын формалаштыру;

мәгариф белән идарә итү органнары җитәкчеләренең игътибарын, потенциалларын нәтиҗәле файдалану өчен, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең казанышларына җәлеп итү;

гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең берләшмәләрен формалаштыру;

гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең һөнәри үсешен (квалификацияләрен) күтәрү;

гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең тәҗрибәсен аларның эшчәнлеге проблемаларын һәм гомумән мәгариф системасын өйрәнү;

гомуми белем бирү оешмаларының иң яхшы җитәкчеләрен бүләкләү.

## 3. Бәйгене оештыру

3.1. Конкурс материалларын бәяләү өчен 11 әгъзасы булган Республика конкурс комиссиясе (алга таба - конкурс комиссиясе) һәм экспертлар саны 20 булган Эксперт комиссиясе төзелә.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда катнашучыларның яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы санала.

3.2 Конкурс комиссиясе карарлары, әгәр аның өчен катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавыш тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Рәис булмаган очракта, конкурс комиссиясе утырышында аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

3.3. Бәйгене оештыру-методик яктан тәэмин итүне һәм уздыруны составында рәис, сәркатиб һәм комиссия әгъзалары булган Республика конкурс комиссиясе гамәлгә ашыра.

3.4. Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы беләң раслана.

3.5. Республика конкурс комиссиясе: массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар аша конкурсны үткәрү шартлары, тәртибе һәм сроклары турында игълан итә;

конкурста катнашучылардан гаризалар һәм материаллар кабул итә;

эксперт төркемен туплый;

конкурска тәкъдим ителгән материалларга бәйсез экспертиза оештыра;

конкурсның беренче (читтән торып катнашу) һәм икенче (турыдан-туры) турларын үткәрүне оештыра;

апелляцияләрне карый;

конкурс биремнәрен әзерли;

конкурс нәтиҗәләрен игълан итү һәм җиңүчеләрне, призерларны һәм лауреатларны бүләкләү тантанасын оештыра;

конкурс нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны оештыра.

3.6. Конкурс материалларын һәм конкурс сынауларын бәяләү өчен, составында рәис һәм комиссия әгъзалары булган эксперт комиссиясе төзелә.

3.7. Эксперт комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.8. Конкурс материалларына экспертиза уздырганда, эксперт комиссиясендә эшләргә бәйсез экспертлар җәлеп ителә ала.

3.9. Экспертлар сыйфатында:

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;

педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем бирү төбәк оешмалары;

югары һөнәри белем бирү оешмалары;

җәмәгатьчелек вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин .

3.10. Конкурс материалларына экспертиза уздырганда:

бирелгән материалларны бәяләү критерийлары нигезендә бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек (шул исәптән конкрет катнашучыны бәяләүдә катнашмаган эксперт комиссиясе әгъзаларына карата да) тәэмин ителә.

3.11. Эксперт комиссиясе:

билгеләнгән срокларда, беренче (читтән торып катнашу) һәм икенче (турыдан-туры) турларда грантка дәгъва кылучыларның конкурс материалларын һәм эшләрен билгеләнгән критерийләр нигезендә бәяли.

3.11.1.Конкурс сынавы форматы: " Өлгермәүчеләрсез мәктәп: минем идарә итү стратегияләрем" темасына эссе (5 биткә кадәр текст).

Конкурс биремнәренең үтәлешен бәяләү 6 критерий буенча башкарыла, аларның һәркайсы 2дән 4кә кадәр күрсәткечне үз эченә ала. Һәр күрсәткечкә туры килү 0 яки 1 балл белән бәяләнә.

| Критерийлар | Күрсәткечләр | Баллар |
|---|---|---|
| текстның тел белеме ягыннан грамоталылыгы (сөйләм, грамматик, орфографик һәм пунктуацион) | сөйләм грамоталыгы | 0 дан 4 кадәр |
| | грамматика өлкәсендә грамоталык | |
| | Орфографик грамоталык | |
| | Пунктуацион  грамоталык | |
| актуальлекне нигезләү | һөнәргә карашның киңлеге һәм масштаблылыгы | 0 дан 3 кадәр |
| | белем бирүнең үсеш тенденцияләрен күрә белү | |
| | практика белән бәйләнеш, заман таләпләренә һәм социум (җәмгыять) ихтыяҗларына игътибар итү | |
| кыйммәт ориентирлары булу | хәзерге заман мәгариф системасының кыйммәт ориентирларын аңлау | 0 дан 2 кадәр |
| | дөньяга караш булу | |
| позициянең дәлиллелеге | дәлилләрнең төгәллеге, фактларны  фикерләрдән аеру | 0 дан 3 кадәр |
| | рәсемле мисаллар һәм фактлар куллану | |
| | нәтиҗәләр һәм гомумиләштерүләр булу | |
| проблемаларны билгеләү | проблемаларны билгеләгәндә (формалаштырганда) | 0 дан 2 кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| (формалаштыру) һәм аларны чишү юлларын күрү. | төгәллек һәм нигезлелек, үз позицияңне бәян иткәндә, әһәмиятлесен ассызыклау һәм эзлеклелек сәләте | |
| | тәкъдим ителгән карарларның стандарт булмавы | |
| бәян итү үзенчәлеге (оригинальлеге) . | сәнгать стиле һәм стандарт булмаган бәян итү | 0 дан 3 кадәр |
| | ачыклык һәм тасвирлылык | |
| | ачыклык һәм бөтенлек | |
| Максималь баллар саны | | 17 |

3.11.2. Конкурс сынавы форматы: "Өй эше-идарә итү тәҗрибәсен тасвирлау» (15 биткә кадәр).

Хезмәт чагылдырырга тиеш:

проблеманы формалаштыруны;

әлеге проблеманы хәл итү чараларын;

аны хәл итү эшчәнлеген тасвирлауны;

ирешелгән нәтиҗәләрне;

алдан планлаштырылмаган нәтиҗәләрне;

килеп чыккан проблемалар һәм аларны хәл итү юлларын.

Конкурс биремен үтәүне бәяләү 4 критерий буенча гамәлгә ашырыла, аларның һәркайсы 3тән 5кә кадәр күрсәткечләрне үз эченә ала. Һәр күрсәткечкә туры килү 0 яки 1 балл белән бәяләнә

| Критерийлар | Күрсәткечләр | Баллы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Проблемаларны аңлау | проблемалары аңлау тирәнлеге | 0 дан 5 кадәр |
| | төп проблема буенча үз позицияңне дөрес һәм аңлаешлы итеп формалаштыра белү. | |
| | фикер алышына торган тема | |

| | | |
|---|---|---|
| | белән фикерләр бәйләнеше. | |
| | тәкъдимнәрнең тормышчанлыгы | |
| | Фактларны фикерләрдән аеру һәм проблеманы объектив карау | |
| ышанычлылык һәм позициясен дәлилләү | алган позициянең ачыклыгы һәм төгәллеге | 0 дан 5 кадәр |
| | үз чыгышыңны төгәл һәм логик эзлеклелектә төзү | |
| | Нигезлелек һәм дәлиллелек | |
| | фикер алышына торган мәсьәләләр буенча башка карашларның һәм фикерләрнең булу мөмкинлекләрен тану | |
| | фикерләрне ныгытучы якты мисаллар һәм образлар, | |
| иҗади якын килү һәм фикерләрнең оригинальлеге | иҗади якын килү һәм тәкъдим ителгән карарларның стандарт булмавы | 0 дан 4 кадәр |
| | фикерләр яңалыгы һәм оригинальлеге | |
| | фикер алышына торган проблемада яңа якларны күрә белү | |
| | шәхси һәм идарә мәсьәләләрен хәл итүдә стандарт булмаган юллар табу | |
| мәгълүмати һәм тел культурасы | педагогик кругозор һәм гомуми эрудиция | 0 дан 5 кадәр |
| | төшенчәләр аппаратын һәм фәнни телне куллануның дөреслеге, фактик хаталарның булмавы | |
| | Сөйләм грамоталылыгы | |
| | заманча белем бирүнең норматив-хокукый базасын белү | |
| | мәгариф үсешенең заманча | |

| | | |
|---|---|---|
| | тенденцияләрен аңлау | |
| Максималь балл | | 19 |

3.11.3. Конкурс сынаулары форматы: презентацияне яклау (15 слайдтан да артык булмаган)

Конкурс биремнәренең үтәлешен бәяләү 4 критерий буенча гамәлгә ашырыла, аларның һәрберсе 5әр күрсәткечне үз эченә ала. Һәр күрсәткечкә туры килү 0 яки 1 балл белән бәяләнә

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| фикерләрнең масштаблылыгы һәм стандарт булмавы | идея һәм тәкъдимнәрнең оригинальлеге стандарт булмавы, (индивидуальлек һәм кызыксынуны күрсәтү) | 0 дан 5 кадәр |
| | идарә итү мәсьәләләрендә яңа якларны күрә белү (иҗади якын килү һәм гаҗәпләндерү сәләте) | |
| | мәгариф үсешенең актуаль мәсьәләләренә һәм хәзерге белем бирүнең норматив-хокукый базасын белүгә аерым игътибарны юнәлтү | |
| | Мәгарифнең Стратегик үсеш юнәлешләрен аңлауны  күрсәтү һәм гамәлдәге проблемаларның конструктив хәл итүдә педагогик җәмәгатьчелек  үз карашы булуын күзаллау | |
| | вакыт таләпләренә һәм социум ихтыяҗларына игътибар итү | |
| тәкъдимнәрнең дәлиллелегге, конструктилы гы | идарә итү проблемаларын хәл итүнең конструктив һәм реалистик юлларын күрү сәләте | 0 дан 5 кадәр |
| | булган проблемаларны нәтиҗәле хәл итү юлларын һәм белем бирү өчен караларның әһәмиятен күзаллау | |
| | Тәкъдимнәрнең тормышчанлыгы  һәм эзлеклелеге, аларны педагогик практикада куллану мөмкинлеге, | |
| | үз позицияңне бәян иткәндә төгәллек, ышанучанлык, эзлеклелек һәм төгәллеклелек (төгәллек һәм нигезлелек) | |

| | | |
|---|---|---|
| | педагогик эшчәнлекнең мәгънәсен аңлау һәм конструктив диалог күнекмәләрен күрсәтү | |
| коммуникацион һәм тел культурасы | Карала торган мәсьәлә буенча сораулар формалаштыра  һәм комментария бирә белү | 0 дан 5 кадәр |
| | сөйләм культурасы һәм төшенчәләр аппаратын дөрес куллану | |
| | башка карашларның хөрмәт итү һәм төрле позицияләргә карата толерант мөнәсәбәт | |
| | фикер алышына торган мәсьәләләрне аңлау, үз карашларыңны бәян итү логик эзлеклелеген һәм гомумиләштерү сәләтен күрсәтү | |
| | үз позицияңне тәкъдим итүдә ышанучанлык, ачыклык һәм төгәллек | |
| кыйммәт ориентирлары булу һәм шәхси позиция | хәзерге мәгариф системасының кыйммәт ориентирларын аңлау һәм дөньяга  карата караш булу | 0 дан 5 кадәр |
| | тәрбия максатларын кую һәм педагогик эшчәнлекнең тәрбия эффектларын аңлау | |
| | укучылар, педагогик хезмәткәрләрнең шәхси ихтыяҗларына һәм мәнфәгатьләренә игътибар итү | |
| | лидерлык сыйфатларының потенциалын ачу, иҗат һәм индивидуальлек чагылышы | |
| | мәгариф системасында гражданлык позициясен формалаштыруга игътибар итү | |
| Максималь баллар саны | | 20 |

3.11.4. Конкурс сынавы форматы: конкурс биреме үтәлешен бәяләү 4 критерий буенча башкарыла, аларның һәрберсе 3тән 4кә кадәр күрсәткечләрне үз эченә ала. Һәр күрсәткечкә туры килү 0 яки 1 балл белән бәяләнә.

| Критерийлар | Күрсәткечләр | Баллар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| нәтиҗәлелек һәм практик кулланылыш | нәтиҗәгә ирешү һәм нәтиҗәләрнең төрлелегенең сан һәм сыйфат күрсәткечләре булу | 0 дан 3 кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| | планлаштырылган нәтиҗәләр белән чагыштыру | |
| | укыту методикаларын һәм технологияләрен транслироваціяләү мөмкинлекләрен һәм һөнәри үсеш перспективаларын аңлау | |
| коммуникатив культура | фикер алышына торган проблемаларның асылын аңлый белү | 0 дан 3 кадәр |
| | Экспертлар  соравына төгәл һәм тулы җаваплар | |
| | булган проблемаларга  киң караш, фикер алышына торган мәсьәләләрдән иң мөһимен аерып ала белү һәм аңа карата үз позицияң булу | |
| оригинальлек һәм иҗади якын килү | фикер алышына торган мәсьәләләрдә яңа якларны күрү | 0 дан 4 кадәр |
| | иҗади якын килү һәм педагогик бурычларның көтелмәгән хәл итү юлларын табу | |
| | индивидуальлек күрсәтү һәм гамәлдәге шаблоннардан читләшү | |
| | чыгышларда һәм сорауларга җавапларда кулланыла торган якты мисаллар һәм образлар | |
| фәнни корректлылык һәм методик яктан грамоталык | тәкъдим ителгән педагогик тәҗрибә нәтиҗәлелеген ышандырырлык һәм дәлилле нигезләү | 0 дан 3 кадәр |
| | педагогик терминологияләрне куллануда төгәллек һәм корректлык  фактик хаталар булмау | |
| | педагогик эшчәнлек тәҗрибәсен тәкъдим итүдә логик эзлеклелек (адымнарны төзү һәм алгоритмнар булу) | |
| мәгълүмати һәм тел белеме грамоталылыгы | сүзнең дөреслеге, фикерләрне белдерүнең ачыклыгы һәм ораторлык осталыгына ия булу | 0 дан 3 кадәр |
| | төрле форматтагы мәгълүматны структуралаштыру (төзү) (текст, график, | |

| | | |
|---|---|---|
| | электрон һ. б.).) | |
| | педагогик кругозор һәм гомуми эрудиция | |
| Максималь баллар саны | | 16 |

3.11.5. Конкурс сынавы форматы: «Мәгарифне үстерү стратегиясе мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл». Конкурс биремнәренең үтәлешен бәяләү 4 критерий буенча гамәлгә ашырыла, аларның һәрберсе 5 күрсәткечне үз эченә ала. Һәр күрсәткечкә туры килү 0 яки 1 балл белән бәяләнә.

| Критерийлар | Күрсәткечләр | Баллар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| коммуникацион һәм тел культурасы | команда эшендә конструктив хезмәттәшлек урнаштыру (тыңлый һәм ишетә белү) | 0 дан 5 кадәр |
| | проектны эшләүгә һәм тәкъдим итүгә җәлеп ителү, булган тәҗрибәне аңлый һәм эшкәртә белү | |
| | сөйләм культурасы һәм төшенчәләр аппаратын дөрес куллану | |
| | Сораулар формалаштыра белү, комментарияләр бирү һәм куелган сорауларга җавап бирү | |
| | дискуссия алып бару культурасы (хөрмәт, башка карашларны аңлау) | |
| карарларның актуальлеге һәм тормышчанлыгы | Проект проблемасының мәгариф өчен әһәмиятен дәлилләү | 0 дан 5 кадәр |
| | проблеманы хәл итүнең төрле юлларын күзаллау, гипотезаны нигезләү һәм карарның дәлилләнүе | |
| | проблемаларны нәтиҗәле хәл итү юлларын һәм чишелешләрнең белем бирү өчен булган әһәмиятен күзаллау | |
| | ресурслар белән тәэмин итүнең хакыйкыйлыгы һәм мөмкин булган хәвефләрне минимальләштерү | |
| | проектны тиражлау потенциалы, белем бирү практикасына тарату һәм гамәлгә кертү мөмкинлеге | |
| нәтиҗәлелек | Проектның куелган максатларына ирешү һәм бурычларын үтәү объективлыгы һәм күрсәтмәлелеге | 0 дан 5 кадәр |
| | нәтиҗәләр фаразлануы, ирешелгән һәм планлаштырылган нәтиҗәләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | чагыштырмасы | |
| | эшчәнлекнең төгәллеге һәм продуктивлыгы (проект продуктлары һәм эффекты) | |
| | белем бирү проектын эшләүдә һәм тәкъдим итүдә чагыштырма алымнарны куллану(иң яхшы тәҗрибәләрне чагыштыру һәм куллану) | |
| иҗат һәм оригинальлек | һәм идея һәм тәкъдимнәрнең стандарт булмавы, оригинальлеге | 0 дан 5 кадәр |
| | фикер алышына торган проблемада яңа якларны күрә белү | |
| | бурычларны үтәгәндә инициатива һәм җаваплылык | |
| | эшчәнлек нәтиҗәләрен бәяләү һәм үз-үзеңне бәяләү адекватлылыгы, төзәтмәләр кертү сәләте | |
| | Иҗат чагылышы, индивидуальлек һәм җавапларның якты стиле | |
| Максималь баллар саны | | 20 |

Баллар эксперт битләренә кертелә, эксперт имзасы белән таныклана һәм эксперт комиссиясе рәисенә тапшырыла.

Эксперт битләре нигезендә грантка дәгъва кылучыларның рейтингы төзелә.

Эксперт комиссиясе рәисе һәм әгъзалары кул куйган Рейтинг Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла

3.12. Эксперт комиссиясе 2017 елның 14 апреленнән 8 маена кадәр бирелгән гаризаларны карый, беренче (читтән торып катнашу ) турда грантка дәгъва кылучыларның эшләренә экспертиза үткәрә

3.13. Эксперт комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча, конкурсның икенче (турыдан-туры) турында катнашу өчен, конкурс грантка дәгъва кылучыларның исемлеге төзелә һәм раслана.

3.14. Конкурсның икенче туры Казан шәһәрендә 2017 елның 15-17 май көннәрендә уза. Эксперт комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча грантка дәгъва кылучыларның рейтингы төзелә (җыелган баллар суммасы буенча) һәм республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

3.15. 2017 елның 18 маенда конкурсның икенче (турыдан-туры) туры нәтиҗәләре буенча республика конкурс комиссиясе грант алучылар исемлеген төзи.

3.16. Грант алучы 2017 елның 18 маенда Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының htpp//: mon.tatar.ru/ “Укытучыларга грантлар” бүлеге/”Безнең иң яшы мәктәп диреторы”/ сайтында грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыра.

## 4.Катнашу шартлары

4.1. Конкурста соңгы биш ел эчендә хәзерге вакытта үзе җитәкләгән мәгариф оешмасында шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе катнаша ала.

4.2. Республика конкурс комиссиясе һәм эксперт комиссиясе әгъзалары конкурста катнашырга хокуклы түгел.

4.3. Алдагы елларда грант алучылар конкурста кабат өч елдан соң гына катнашырга хокуклы.

4.4. Конкурста катнашу өчен гантка дәгъва кылучы шәхсән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе(алга таба - «Мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАМУ) сайтында конкурста катнашучы сыйфатында теркәлергә һәм «Мәгарифне үстерү институты» ӨББ ДАМУ нә үзенең материалын — эссе һәм идарә тәҗрибәсе тасвирлармасын җибәрергә тиеш.

4.5. Грантка дәгъва кылучының барлык конкурс чаралары турында тулы мәгълүматны үз вакытында алырга; бирелгән материалларның һәм конкурс сынауларының объектив бәяләневенә хокукы бар.

4.6. Гантка дәгъва кылучы конкурс регламентын үтәргә тиеш.

4.7. Конкурс материаллары процессларның, идеяләрнең, тәкъдимнәрнең, тәҗрибәнең асылын кыска, аңлаешлы формада чагылдырырга тиеш.

4.8. Конкурска тәкъдим ителгән материаллар кире кайтарылмый. Күрсәтелгән сроктан соң яки аларга куела торган таләпләргә җавап бирми торган материаллар конкурста катнашмый һәм гантка дәгъва кылучы кире кайтарылмый.

4.9. Республика конкурс комиссиясенә материаллар тәкъдим итеп, Гантка дәгъва кылучы республика комиссиясе һәм эксперт комиссиясе тарафыннан конкурс максатлары өчен бирелгән шәхси мәгълүматларны куллануга ризалык бирә

5.Конкурс үткәрү регламенты

5.1. Конкурста катнашу өчен , 2017 елның 14 апреленә кадәр Гантка дәгъва кылучыга : катнашучының мәгълүмати картасын, конкурсөчен эссе һәм фотогсурәт тапшырырга кирәк. Документлар электрон адреска msairort@yandex.ru «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең аттестация һәм һөнәри конкурсларны оештыру-методик тәэмин итү бүлегенә җибәрелә.

5.2. Конкурс ике турда үткәрелә:

беренче тур —2017 елның 8 маена кадәр бирелгән тема буенча эссе һәм «Өй эше - идарә тәҗрибәсен тасвирлау» конкурс сынавын үтәү ;

икенче тур- 2017 елның 15-17 маенда идарә тәҗрибәсен күрсәтү (идарә эшчәнлеген тәкъдир итү һәм конкурс сынаулары).

5.3. Беренче (читтән торып катнашу) тур ике этапта үткәрелә:

5.3.1. Беренче турның (2017 елның 17-19 апреле) беренче (читтән торып катнашу) этабында, әлеге Нигезләмәнең 3.11.1 пункты критерийлары нигезендә, конкурска тәкъдим ителгән эссене бәяләү үткәрелә.

5.3.3. 2017 елның 21 апрелендә «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " ӨҺББ ДАМУ сайтында беренче (читтән торып катнашу) турның икенче этабына кертелгән гантка дәгъва кылучыларның исемлеге басыла. Исемлек катнашучының эссесе эксперт бәяләве нигезендә төзелгән рейтинг буенча формалаша.

5.4. Конкурсның беренче (читтән торып катнашу) турының беренче этабын үткәрү нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, Гантка дәгъва кылучы республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, конкурсның беренче (читтән торып ккатнашу) турының икенче этабына грантка дәгъва кылучыларны чыгару турында Республика конкурс комиссиясе карары «ТР Мәгарифне үстерү

институты» ӨҺББ ДАМУның рәсми сайтында басылып чыккан  көннән башлап,  эш көннәрендә исәпләнгән өч көн срокта, республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә «ТР Мәгарифне үстерү институты» ӨҺББДАМУның рәсми сайты, «Грантлар " бүлеге, «Безнең иң яхшы мәктәп директор» бите аша  ирекле язма фомада бирелә.

5.5.  Республика конкурс комиссиясе апелляцияне, апелляция бирү вакыты тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнгән ике көнлек срокта карый. Республика конкурс комиссиясе конкурс материалларын бәяләгәндә, эксперт комиссиясе тарафыннан хокук бозулар булу-булмавын билгели , шулай ук ул бәяләү балларын аргументацияләү өчен экспертларны чакыру хокукына да ия. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияләрне канәгатьләндерү, грантка дәгъва кылучыны  беренче (читтән торып катнашу) турның икенче этабына чыгару һәм конкурсның беренче (читтән торып) турының икенче этабында катнашучылар исемлегенә кертү турында.

Апелляция буенча Республика конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучылар саныннан гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, республика конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы.

5.6. Республика конкурс комиссиясе  тарафыннан апелляцияне карау комиссия утырышында катнашучы республика конкурс комиссиясе рәисе һәм барлык әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.7. Конкурсның беренче (читтән торып катнашу) турының икенче этабына кадәр кертелгән грантка дәгъва кылучы  «Өй эше - идарә тәҗрибәсен тасвирлау» конкурс сынавын үтәргә тиеш, биремәр 2017 елның 2 маенда аларга электрон почта аша җибәреләчәк. Биремнәрне үтәү нәтиҗәләрен «Мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАМУсенә 2017 елның 8 маена кадәр җибәрергә кирәк.

5.8. «Өй эше - идарә тәҗрибәсен тасвирлау» конкурс биреме, әлеге Положениенең 3.11.2 пунктында билгеләнгән критерийлар нигезендә, эксперт комиссиясе тарафыннан бәяләнә.

5.9. 2017 елның 12 маенда «Мәгарифне үстерү институты " ӨҺББ ДАМУ сайтында икенче (турыдан-туры) турга кертелгән 20 кешедән торган катнашучылар исемлеге бастырыла.

5.10. Икенче (турыдан-туры) турга кертелгән грантка дәгъва кылучыларга шәхсән Казанга килергә кирәк. Катнашучыларның даими яшәү урыныннан Казан шәһәренә килү һәм кире кайту, шулай ук Казан шәһәрендә яшәү грантка дәгъва кылучылар хисабына түләнә.

5.11. Конкурсның икенче туры 2017 елның 15-17 маенда Казан шәһәрендә үткәрелә.

5.12. Икенче (турыдан туры) турда грантка дәгъва кылучылар түбәндәге конкурс сынаулары уза:

өй эшен тәкъдир итү;

шәхси чыгыш;

түгәрәк өстәлдә катнашу.

Беренче (читтән торып) тур нәтиҗәләре бу вакытта исәпкә алынмый.

5.13. «Өй эше - идарә тәҗрибәсен тасвирлау» конкурсы биремен(15 слайдтан артык булмаган) тәкъдир итү әлеге Положениенең 3.11.3 пунктында билгеләнгән критерийлар нигезендә эксперт комиссиясе тарафыннан бәяләнә.

5.14. конкурс биреме «Өй эше» -идарә тәҗрибәсен тасвирлау ны тәкъдир итү өчен куелган баллар алынган баллар буенча бердәм рейтингка формалаша.

5.15. Рейтингта 11-20 урын алган грантка дәгъва кылучыларга " (10 кеше) “Конкурс лауреаты»статусы бирелә.

5.16. 1-10 нчы урынны алган грантка дәгъва кылучыларга (10 кешегә) «Шәхси чыгыш” конкурс сынавы темасы чыгыш алдыннан бәяләү критерийлары белән бергә (әлеге Положениенең 3.11.4 пункты) бирелә

5.17. Эксперт комиссиясе тарафыннан «Шәхси чыгыш» конкурс сынавы өчен куелган баллар бердәм рейтингка формалаша.

Беренче (читтән торып катнашу) тур нәтиҗәләре бу вакытта исәпкә алынмый.

Йомгаклау рейтингын билгеләгәндә, нәтиҗәләр тигез булган очракта, республика конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

5.18. Рейтингта 6-10 урынны алган грантка дәгъва кылучыларга (5 кешегә) " Конкурс призеры» статусы бирелә.

5.19. Рейтингта 5тән 1гә кадәр урын алган грантка дәгъва кылучылар «Мәгарифне үстерү стратегиясе мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл»конкурс сынавына кертелә.

5.20. ” Мәгарифне үстерү стратегиясе мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл " Конкурс сынавының темасы грантка дәгъва кылучыларга (әлеге Положение нең п. 3.11.5 бәяләү критерийлары белән) сынау алдыннан атала һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары — Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры Э. Н. .Фәттахов катнашында түгәрәк өстәл рәвешендә үткәрелә.

5.21. Эксперт комиссиясе тарафыннан «Мәгарифне үстерү стратегиясе мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл» конкурс сынаулары өчен куелган баллар бердәм рейтингка формалаша.

Икенче (турыдан-туры) турның алдагы конкурс сынаулары нәтиҗәләре бу вакытта исәпкә алынмый. Йомгаклау рейтингын билгеләгәндә нәтиҗәләр тигез булган очракта, республика конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

5.22. Рейтингта 2-5 урынны алган грантка дәгъва кылучыларга (4 кеше) "Конкурс җиңүчесе» статусы бирелә.

5.23. 1 нче урынны алган грантка дәгъва кылучыга "Конкурсның абсолют җиңүчесе» статусы бирелә.

## 6. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне, призерларны һәм лауреатларны бүләкләү тәртибе

6.1. Конкурска йомгак ясау республика конкурс комиссиясе тарафыннан икенче (турыдан-туры) тур тәмамланганнан соң үткәрелә.

6.2. Грант алучыларны игълан итү һәм бүләкләү бүләкләү тантанасында үткәрелә.

## 7.Бәйгене финанслау

7.1. Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.